
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР СУКСУЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

423736, Татар Суксуы авылы,
Гагарин ур.,1 б нче йорт.
Тел. 3-44-60

e-mail: tsuk-akt@yandex.ru



РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТАТАРСКО-СУКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТАТАРСКО-СУКСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423736, с. Татарские Суксы,
ул. Гагарина, дом 1 б.
Тел. 3-44-60
e-mail: tsuk-akt@yandex.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

«17» декабрь 2021 ел №25

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксы авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 14 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеше), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Татар Суксуы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Советының, 2014 елның 20 ноябрендәге 14 номерлы «Җир салымы турындагы» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Дәүләт автоном һәм бюджет учреждениеләренең милек хокукындагы яисә муниципаль автоном һәм бюджет учреждениеләреннән даими сроксыз файдалану хокукындагы объектлардан тыш, мәгариф, фән, физик культура һәм спорт, сәнгать объектлары билгән җир кишәрлекләренә карата 1,5%;».

1.2. 2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге12 нче абзац белән тулыландырырга:

«-сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат объектлары билгән җир кишәрлекләренә карата 0,6%».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Татар Суксуы авылы, Гагарин урамы, 1Б нче йорт, адреслары буенча, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы, Актаныш авыл җирлеге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Татар Суксуы авыл җирлегенең рәсми сайтында», «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет-телекоммуникация челтәрендәге бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татар Суксуы авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Г.Г.Хамматуллина